ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.04.2021 г. М ө с л и м № 161

**«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 сентябрендәге 574 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**
**(2017 елның 26 декабрендәге 784 номерлы редакциясендә)**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 17 мартындагы 20-08/3184 номерлы хатын карау нәтиҗәләре буенча, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чараларын күрсәтү турында» Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 сентябрендәге 574 номерлы карары белән расланган Компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәреш кертергә:

- 1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«Компенсация алу хокукын һәм айлык пособие билгеләгәндә гаилә әгъзаларының җан башына керемнәре балага айлык пособие билгеләү турында гариза бирү ае алдыннан алты календарь айга кадәр булган соңгы 12 календарь айдагы керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә».

2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль-мәдәни үсеш буенча урынбасары М.Р. Бәдретдиновага йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Р.Т. Демидов**